ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 73 от «19» 02 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының тәрбиягә бала алган гаиләләреннән дәүләт оешмаларына балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Опека һәм попечительлектә булган һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә яшәүче балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2016 елның 19 маендагы 14-16 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы гаиләләреннән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турында» 2016 елның 26 июлендәге 1437/16 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 сентябрендәге 1188 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының тәрбиягә бала алган гаиләләреннән дәүләт оешмаларына балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 7.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

Нигезләмәнең 7.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре кул куйган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

0000010780

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов